**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2024 № 1522

.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге “Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе составындагы методик һәм мәгълүмати вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы мәгълүмат - методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 31 мартындагы 380 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, 2001 елның 30 декабрендәге 197-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Нурлат муниципаль районының «мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 380 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 2 пунктына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**База оклады (база вазыйфаи оклады), хезмәт хакының база ставкасы** - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче һөнәре яки хезмәткәр вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы дәүләт яисә муниципаль учреждение хезмәткәренең минималь оклады (вазыйфаи оклады), хезмәт хакы ставкасы»;

– 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Оклад (вазыйфаи оклад)** - фиксированный размер оплаты труда работника за исполнение трудовых (должностных) обязанностей определенной сложности за календарный месяц без учета компенсационных, стимулирующих и социальных выплат.»;

– 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) -** хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация түләүләре

(компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән нормаль шартлардан читкә тайпылган шартларда эшләгән өчен, махсус климат шартларында һәм радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә эшләгән өчен, һәм компенсация характерындагы башка түләүләр) һәм кызыксындыру түләүләре (кызыксындыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында. (nurlat.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин